

Тарихи, сәяси, мәдәни вакыйгалар, һичшиксез, кешеләрнең тормышына, аларнын рухи-әхлакый карашларына, vсешенә тәэсир итә. Аерым кешенен язмышы - анын герой һәм фажигале битләре белән билгеле бер чорнын дореслеген чагылдырган козге. Шулай, Атюрьево районында олкән буын вәкилләрен «Сугыш чоры балалары» медальләре белән бvләкләv дәвам итә.
Боек Ватан сугышы һәр совет гаиләсе тормышына керде. Кызганычка каршы, Атюрьево районында әлеге коточкыч вакыйгаларда катнашучылар калмаган, әмма, бәхеткә каршы, сугыш елларын яхшы хәтерләвче «Сугыш чоры балалары» исән әле.      Аларнын балачагы юк иде дип әйтергә була. Кvпчелек гаиләләрдә сугыш елларына балачаклары туры килгән туганнары бар, ләкин гади кызлар һәм малайларнын ничек яшәгәннәрен бик аз кеше белә; аларга тvзәргә һәм авыр тормыш кичерергә туры килгән. «Сугыш балалары» - хәзерге әби - бабайлар буыны. Сугыш аларнын якты һәм шатлыклы балачагын тартып ала, балалар язмышларын гарипләндерә, чонки сугыш башы алар очен тормыш башлану белән туры килә. Аларнын балачагы 1941 елнын 22 июнендә озелә.
Үткән ел азагында Атюрьево районы ветераннар советы рәисе, авыл жирлекләре башлыклары белән берлектә, берничә  ветераннын  ойләренә  барып, аларны бvләкләгәннәр. Бvләкләнvчеләр арасында олкән буын вәкилләре, авыр сынаулар һәм югалтулары кvп булган кешеләр, шулай ук Ватаннары һәм туган яклары исеме һәм чәчәк атуы очен кvпьеллык авыр хезмәтләре белән аерылып торганнар. Алар арасында Шамиль Мифтах улы Вергасов (10.09.1934 елда туган) бар. Ул, Пишляй авылында яшәvче авыл халкынын абсолют кvпчелеге кебек, vзенен хезмәт биографиясен мәктәп елларында башлаган бала. Шамиль Мифтах улы олкәннәргә кырда һәм ойдә ярдәм иткән яшьтәшләре арасында. Мәктәпне тәмамлаганнан сон оч ел армиядә хезмәт итә, ә 1956 елда, мобилизацияләнгәннән сон, ул 1995 елда лаеклы ялга чыкканчы, башта туган районынын «Партизан» совхозында, ә аннары 1989 елдан яна «Колопинский» совхозында намус белән хезмәт итә.
- Полуторкадан башлап, - дип искә ала «Хезмәт ветераны», - аннары ГАЗ-53дә эшләдем, ә пенсиягә КамАЗ шоферы буларак чыктым, - ди.
Зирәк акыллы, ярдәмчел, кешелекле Шамиль Мифтах улынын бvгенге кондә 11 оныгы һәм 6 оныкчыгы бар, дип горурланып әйтә ул. Язма героебыз «Почет Билгесе» ордены

кавалеры, торле дәрәжәдәге Мактау грамоталары һәм бvләкләр иясе.
Чираттагы «Сугыш балалары» медален тапшырып, Иван Андреевич Козяйкин, Ветераннар советыннан һәм шәхсән vз исеменнән район һәм Ватаныбызнын чәчәк атуы очен озак еллар намуслы хезмәте очен рәхмәт белдереп:
- Сез сугыш еллары авыр сынаулары һәм хужалыкларнын жимереклегеннән сугыштан сонгы терелv кичергән буын вәкиле. Бала буларак, сезгә иртә олыгаерга, фронтка киткән әтиегезне һәм абыйларыгызны алыштырырга мәжбvр булдыгыз. Сезнен буын яшь буыннын хормәтенә лаек, яшьләр хәзер сездән vрнәк алырга тиешләр...
Лаеклы бvләкне ветеран тирән рәхмәт хисләре белән кабул итте.

**Н.ХӘЛИЛ**